Татар әдәбияты
8нче класс

# “Аяз Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” повестенда шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре” дәрес планы һәм конспекты

“Балык Бистәсе 2нче
номерлы гомуми урта белем
бирү мәктәбе” МГББУ укытучысы
Токранова Эльвира Ильяс кызы

**Тема:** Аяз Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” повестенда шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре.

**Максатлар:**
1. А.Гыйләҗевның “Язгы кәрваннар” әсәрендә шәхес белән җәмгыять мөнәсәбәтләрен ачыклау.
Тема аша язучы иҗатының төп мәгънәви юнәлешләренә төшендерү;

2. Сәбәп- нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыра белү;
Текст һәм дәреслектән файдалану күнекмәләрен ныгыту;
Төркемнәрдә эш ысулларын ныгыту;
Текст белән эш күнекмәләрен ныгыту;
Монологик сөйләмнең нормаларын кулланырга өйрәтү.

3.Әдәби әсәрләр укуга, язучы иҗатына кызыксыну тәрбияләү.
Әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** белемнәрне ныгыту дәресе

**Методлары:**
1. Күрсәтү-аңлату;
2. Эзләнү;
3. Әңгәмә;
4. Сүзлекләр,текстлар белән эш;
5. Төркемнәрдә эш;
6. Гомумиләштерү һәм нәтиҗәләр ясау;

**Дәресне җиһазлау:** Ярдәмлек һәм белешмә әдәбият, мультимедиа презентация, язучы китапларыннан күргәзмә, биремнәр язылган карточкалар һәм текстлар.

**Кулланылган әдәбият:**

1. А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Ә.Ганиева. Әдәбият Татар урта гомуми белем мәктәбенең 9нчы сыйныфы өчен дәреслек- хрестоматия- Казан, “Мәгариф”, 2006
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге.- Казан: Мәгариф, 2007.-231 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.Ф.Ганиев ред.- Казан: “Матбугат йорты”, 2005
4. Татар әдәбияты тарихы. 6нчы том. 60-90нчы еллар.- Казан. “Раннур”,2001
5. А.Гыйләҗевның китаплары.

## Дәрес планы:

**I.** Актуальләштерү. Укытучы сүзе.
**II.** Яңа тема.
**III.** Белемнәрне ныгыту. Төркемнәрдә эш.
**IV.** Йомгаклау. Өй эше. Дәрескә нәтиҗә, билгеләр кую.

## Дәрес конспекты:

| Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге |
|---|---|
| **I.**-Исәнмесез, укучылар! Мин бүгенгә сезнең татар әдәбияты укытучыгыз булып торырмын. Без бүген һәр дәрестәгечә утырмадык. Мин сезнең бер- берегезгә ярдәм итеп, янәшә утыруның җылылыгын тоеп эшләвегезне телим.Сез бер җәмгыять. Төркемнең лидерлары бүген...,... Бүгенге дәрес һәркайсыбыз өчен файдалы булыр дип өметләнәм.<br>Әйтегез әле, сезне алдаганнары, кыерсытканнары бармы? Сез мондый очракта ни эшлисез, нинди хисләр кичерәсез? Әгәр дә сезне өлкәннәр кыерсытса, кимсетсә? Әгәр дә сезне шул чакта кем дә булса якласа, сез аңа рәхмәтлеме?<br>Укучылар, кызганыч, кешелек законнарын бозсалар да, кайбер кешеләрнең гаделсезлегенә без куркып күз йомабыз, я әйтми калу яхшырак дип уйлыйбыз. Кешеләрнең бергә яшәү даирәсе “җәмгыять” дип атала. Әйдәгез, аның төгәлрәк билгеләмәсен белик әле, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”нә мөрәҗәгать итәбез. “Тормышта аерым бер тарихи шартларда берләшкән кешеләр бергәлеге” Димәк, бер заманда яшәүчеләр без барыбыз да җәмгыять.<br>Бәхеткә каршы, кешелек җәмгыятенең уңышсыз якларын ачып салучылар да бар безнең арада. Шундыйларның берсе- язучы А.Гыйләҗев. Аның тормыш юлын искә төшерик әле.<br>Укучылар, язучы биографиясендә аның иҗат тематикасына нык тәэсир иткән, дәреслектә язылмаган эпизодлар да бар. Димәк, аның уй- фикерләре һичкемгә зыян китермәсә дә, җәмгыятьнең кайбер вәкиләре башкача уйлаган, төрле әләкләүләр аркасында егетне университеттан куалар һәм ирегеннән мәхрүм итәләр. Язучы башка сез белгән күп язучылар: Х.Туфан, Ш.Усманов, Г.Ибраһимовлар кебек үк .1950-1955нче елларда сөргендә булу да | *Көтелгән җаваплар:*<br>-*Әйе.*<br>- Ачу килү, аралашмау, елау, кемгәдер ярдәмгә мөрәҗәгать итү<br>- Дәшми калырга да мөмкин. Ачуыңны йоту, яки аралашмау.<br>- Әйе, әлбәттә.<br><br>1 укучы тормыш этаплрын искә төшерә. |

| | |
|---|---|
| язучының хөр уйларын бүлми,  ул әсәрләрендә кешелек кануннарын бозучыларны фаш итүне дәвам иткән.<br>**II.** Сез өйрәнгән “Язгы кәрваннар” әсәре җәмәгатьчелектә зур бәхәс уяткан әсәрләрнең берсе. Әсәр ни турыда? Менә хәзер төркемнәрдә эш башлыйбыз. Кем барлык тематик яссылыкларны да билгели алыр икән? Арада иң әһәмиятлесе төп тема була. Безнең максатыбыз- шуны ачыклау. | - төркемнәр тематиканы билгели.<br>1 Сугыштан соңгы чорда авыл халкының авыр тормышы.<br>2 Кешеләрнең үзара ярдәмчеллеге, бердәмлеге.<br>3 Мәхәббәт.<br>(4 Җәмгыятьнең гаделсезлеге) |
| Мәхәббәт темасы кайсы образлар аша тасвирлана? Әдилә белән Ибраһимның хисләре ничек күрсәтелә?<br>2,3 темалар буенча төркемнәрдә сөйләшик әле. Һәр төркем әсәрдә нәкъ шушы тема булуына дәлилләр табарга тиеш. | 1 Ашарларына юк. Колхозда симәнә дә калмаган. Бергә ашаган чактагы ризыклар. Киенү рәвешләре.<br>2 Ибраһим, Дамирның барысы өчен чана тартуы. Ярлы күршеләрдән үзләренә өйгә чакырулары. |
| **Ял минуты.** Басабыз. Кулларны тоташтырабыз- чылбыр буенча, үзәккә. Кулларыбызны иң башына куябыз. Аркаларны терәп басабыз. Мин сезнең шушындый бердәм булуыгызны телим, укучылар. | Ял моменты. Физик күнегүләр. |
| **III** Бәлки төркемнәрнең бер- берләренә сораулары бардыр? Мин сезгә укытучыгыз аша өй эшләре биргән идем. Ул сугыштан соңгы чор балалары., ягъни сезнең әби- бабаларыгыз бала чакта күргәннәрен сорашырга иде. Әйдәгез сөйләп карыйк әле. | -берничә укучы фикере. |
| Укучылар. Ни кызганыч, сез әсәрне ничаклы җентекләп өйрәнсәгез дә, дәреслектә тиешле өзек китерелмәве аркасында әсәрдәге бер темабыз төшеп калган. Аны ачыклау өчен мин сезгә әсәрнең тулы вариантыннан өзек тәкъдим итәм. Ул ни турыда, ачыклыйк әле.<br>-Кәслегә кешеләр ни өчен барган иде?<br>- Аларның авылы кайсы глубинкага якынрак?<br>- Сабирәттәй нигә үлә?<br>- Каршыга очраган кешеләр Сарсазга нигә киләләр?<br>- Алар әйткән сүзләр белән килешәсезме?<br>- Хәкимҗан абый ни эшләп йөргән?<br>- Ул нигә Әдилә белән Ибраһимга дөреслекне әйтергә кушмый? | *Укучыларга биремнәр язылган карточкалар тәкъдим ителә. Алар  төркемнәрдә сорауларга җавап әзерлиләр һәм кем җавап бирәчәген ачыклыйлар.*<br>*Сорауларга җаваплар алына, өстәмәләр кертелә.* |
| Әлеге вакыйганың килеп чыгуы- кемнәрнеңдер уйлап бетермәвендә. Ә бит ул кеше гомеренең өзелүенә сәбәче булды. Җәмгыятьтә һәркемнең үз урыны бар дигән идек. Кеше шул урынны бизәп тора. Үз вазифаларын төгәл башкарган кешеләр булган җәмгыять гадел булачак. Мин сезгә җәмгыятьтә үз урыныгызны табарга дип теләк белдерәм.<br>Дәрес тәмам. Уңышлар сезгә. | |

| | |
|---|---|
| **IV**Төркемнәрнең эшен бәяләү, укучыларга билгеләр кую. Өй эше.Д: 297-298б. С.Сөләймsecurelyованың биографиясен укырга.Иҗади бирем:Шагыйрәнең шәхесенә хас кызыклы мәгълүматларны өстәмә әдәбияттан табарга. | |

# Дәрескә кулланмалар

Әсәрдән өзекне игътибар белән укыгыз.Сорауларга җавап биргәндә текстка мөрәҗәгать итегез.

-Кәслегә кешеләр ни өчен барган иде?
- Аларның авылы кайсы глубинкага якынрак?
- Сабирәттәй нигә үлә?
- Каршыга очраган кешеләр Сарсазга нигә киләләр?
- Алар әйткән сүзләр белән килешәсезме?
- Хәкимҗан абый ни эшләп йөргән?
- Ул нигә Әдилә белән Ибраһимга дөреслекне әйтергә кушмый?

Әсәрдән өзекне игътибар белән укыгыз.Сорауларга җавап биргәндә текстка мөрәҗәгать итегез.

-Кәслегә кешеләр ни өчен барган иде?
- Аларның авылы кайсы глубинкага якынрак?
- Сабирәттәй нигә үлә?
- Каршыга очраган кешеләр Сарсазга нигә киләләр?

- Алар әйткән сүзләр белән килешәсезме?
- Хәкимҗан абый ни эшләп йөргән?
- Ул нигә Әдилә белән Ибраһимга дөреслекне әйтергә кушмый?

Класста бер укучы дәрес әзерләмәгән. Укытучы классны берничә кат кисәткән, тәртип өчен”2”ле куячагын әйткән. Шулай эшләгән дә.Укытучы хаклымы?

Класс конкурста катнашырга җыена.Аның өчен бер проект эшләргә кирәк.Саниягә бу эшне кушканнар иде,ул авырып китте. Эшне Дамирга йөкләделәр. Берничә көннән соң Сания мәктәпкә килде. Дамир эшне эшләмәде. Ә Сания проект эшләнмәгәнлекне белми калды. Кем гаепле?